РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2026 № 1-21

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 01 февралендәге 12-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 01 февралендәге 12-2 номерлы карарына ( 03.06.2021 № 21-1, 07.09.2021 № 27-2, 16.02.2022 № 40-1, 09.06.2023 № 71-2, 02.06.2025 № 98-1 ред) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарга Кушымтаның 2 статьясындагы 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатның вәкаләтләре чоры ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советының (алга таба - Совет) тулы хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән туктатыла, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында әлеге Нигезләмәнең 4 статьясында каралган очраклардан тыш.»

1.2. Карарга кушымтаның 5 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен эш бирүче тарафыннан эш урынын (вазыйфасын) саклап калып эшләүдән азат ителү гарантияләнә, бу чорның дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм гомумән алганда аена ике эш көненнән дә кимрәк һәм алты эш көненнән артыграк була алмый..»

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адрес

буенча  һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шәрәфетдинов